ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 4-2/г

Татарстан Республикасы халкына көнкүреш ихтыяҗлары өчен сатыла торган сыегайтылган газга 2018 елга ваклап сату бәяләрен билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газга һәм аны җитештерү чималына бәяләрне дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Халыкка көнкүреш ихтыяҗлар өчен сатыла торган сыегайтылган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2007 елның 15 июнендәге 129-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына көнкүреш ихтыяҗлар өчен сыегайтылган газга түбәндәге күләмнәрдә календарь буенча бүленгән ваклап сату бәяләре билгеләргә (НДС исәпкә алып):

1.1. 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр:

- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 27,66 сум;
- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 32,04 сум;

1.2. 2018 елның 1 июленнән 2018 елның 31 декабренә кадәр:

- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 28,60 сум;
- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 33,13 сум;

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов